**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.07.2025 № 720

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм чарасы күрсәтү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 1, 2 пунктлары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, 20 статьясындагы 5 өлешенең икенче абзацы, 43 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнар (контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләре), махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә башкаручы гражданнар (ихтыярилар), Россия Федерациясе гвардиясе, Татарстан Республикасында төзелгән "Алга" һәм "Тимер" батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) (алга таба – гаиләләр) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) каты ягулык белән тәэмин итү рәвешендә (озынлыгы 1,5 метрдан 3 метрга кадәр булган яфраклы токымлы технологик утын (алга таба – каты ягулык), аны китерүне дә кертеп шул исәптән хәрби хезмәткәрләр һәм милли хәрби хезмәттә хезмәт итүче затлар арасыннан өстәмә ярдәм чарасы билгеләргә.

2. Күрсәтелгән ярдәм чарасы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затларга ике елга бер тапкыр күрсәтелә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында каралган өстәмә ярдәм чарасын күрсәтү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

4. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм илтеп җиткерүгә бәйле күрсәтелгән өстәмә ярдәм чарасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы дип Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлегенең махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре белән эшләү буенча белгечне өстәмә ярдәм күрсәтүнең кушымта итеп бирелгән тәртибе нигезендә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык белән тәэмин итү рәвешендә, аны илтеп җиткерүне дә кертеп, билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән өстәмә ярдәм чарасын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итәргә..

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1

июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының  2025 елның 02 июлендәге 720 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү рәвешендә, аны китереп бирүне дә кертеп, өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибе**

1. Әлеге тәртип махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык (озынлыгы 1,5 м дан 3 м га кадәр булган яфраклы агачтан әзерләнгән технологик утын) – (алга таба – каты ягулык) белән тәэмин итү рәвешендә, шул исәптән аны кайтарып бирүне дә кертеп өстәмә ярдәм күрсәтү шартларын һәм күләмнәрен билгели.

2. Каты ягулык (озынлыгы 1,5 м дан 3 м га кадәр булган яфраклы агачтан технологик утын) бары тик мич белән җылытыла торган, шул исәптән утыннарда эшли торган автоном җылыту системасы (алга таба - Мич белән җылыту) белән җылытыла торган бер бүлмәгә 5 (биш)куб метр күләмендә бирелә..

3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык белән тәэмин итү һәм илтеп җиткерү чараларын оештыру белән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлегенең махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре эше буенча белгече (алга таба – белгеч)шөгыльләнә.

4. Каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм китереп бирүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасы күрсәтелә торган махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәге затлар аңлашыла (алга таба-гаилә әгъзасы):

махсус хәрби операциядә катнашучының яшәү яисә булу урыны буенча теркәлгән аның балигъ булмаган балалары һәм хатыны яисә (ире);

махсус хәрби операциядә катнашучының ата-анасы.

5. Әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән гаилә әгъзаларына каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм китереп биру гәбәйле өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү мөрәҗәгать итү характерында була.

6. Каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм илтеп җиткерүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасын алу максатында әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән гаилә әгъзасы белгечкә әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасындагы форма буенча түбәндәге документлар белән гариза бирә:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ;

махсус хәрби операциядә катнашучы статусын раслый торган документ;

гаилә әгъзасының һәм махсус хәрби операциядә катнашучының туганлыгын (үзлеген) раслый торган документ (туу (уллыкка алу) турында таныклык, никах турында таныклык, туганлыкны (үзлеген) раслый торган башка документ);

җылыту мич булуы турында мәгълүматны үз эченә алган документ;

махсус хәрби операциядә катнашучының вафат булуы турында таныклык-махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучының гаилә әгъзалары булган затлар өчен.

Гаризада кабул ителгән карар турында хәбәр итү ысулы күрсәтелә (шул исәптән почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы).

Документларның күчермәләрен гаилә әгъзасы һәр кәгазьдә шәхси имза кую юлы белән таныклый.

Документларның күчермәләрен тапшырганда, документларның төп нөсхәләре карап чыгу өчен күрсәтелә.

Гаилә әгъзасы гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

7. Кергән документлар аларны тапшырган көнне белгеч тарафыннан теркәлә.

8. Гариза Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

җитәкчесе тарафыннан теркәлгән көннән алып 10 (ун) эш көненнән артмаган вакытта карала.

9. Гаризаны карау йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

каты ягулык белән тәэмин итү һәм илтеп җиткерү турында(озынлыгы 1,5 м дан 3 м га кадәр булган яфраклы технологик утын);

каты ягулыкны (озынлыгы 1,5 м дан 3 м га кадәр булган яфраклы технологик утын) тәэмин итүдән һәм илтеп җиткерүдән баш тарту турында.

Күрсәтелгән карар язма хәбәрнамә рәвешендә гаилә әгъзасына гаризада күрсәтелгән ысул белән әлеге Тәртипнең 8 бүлегендә билгеләнгән гаризаны карау вакытыннан да соңга калмыйча җибәрелә.

10. Каты ягулыкны тәэмин итүдән һәм китереп бирүдән баш тарту өчен нигезләр булып:

әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән затлар категориясенең туры килмәве;

тапшырылган документларда дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән мәгълүмат ачыкланды;

җылыту миче булмау;

чистартылган яисә өстәп язылган документларны, сызылган сүзләрне һәм аларда килештерелмәгән башка төзәтмәләрне, документның текстын укырга һәм аның эчтәлеген бер мәгънәдә аңлатырга мөмкинлек бирми торган төзәтмәләр кертеп тапшыру;

гаилә әгъзасы тарафыннан гаризаны кире алу;

әлеге Тәртипнең 6 бүлегендә күрсәтелгән документларның тулы булмаган җыелмасын тапшыру.

11. Баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәндә каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм китереп бирүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасын күрсәтү өчен документлар әлеге Тәртип нигезендә белгечкә яңадан тапшырылырга мөмкин.

12. Каты ягулыкны гаилә әгъзасы күрсәткән адрес буенча илтеп җиткерү каты ягулыкны тәэмин итү һәм китереп бирү турында Карар кабул ителгән вакыттан алып 30 (утыз) календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.